| ГЛАВА АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2019 Әгерҗе ш. № 94

«Әгерҗе шәһәрендә К. Маркс урамын төзекләндерү» проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 46 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль район Советының 2018 елның 27 июнендәге 28-2 номерлы карары белән расланган җәмәгать тыңлауларын, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 28 декабрендә кабул ителгән 33-2 номерлы «Җәмәгать тыңлауларын, иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» карарына таянып карар итәм:

1. «Әгерҗе шәһәрендә К. Маркс урамын төзекләндерү» проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын билгеләргә.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, торак – коммуналь хуҗалык, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген- җәмәгать фикер алышуларын оештыручы итеп билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Җәмәгать фикер алышуларын уздыру датасы-2019 елның 19 декабре;

2.2. "Әгерҗе шәһәрендә К. Маркс урамын төзекләндерү» проекты концепциясен бастырып чыгару өчен рәсми сайт - http://agryz.tatarstan.ru.

2.3. Җәмәгать фикер алышуларын үткәрү урыны - 422230, ТР, Әгерҗе ш., Гагарин ур., 68А «Әгерҗе шәһәре Яшьләр үзәге»;

3. Җәмәгать фикер алышуларын оештыручыларга:

3.1. Әлеге карарны Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http://agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru , шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының мәгълүмат стендларына урнаштырып бастырып чыгарырга;

3.2. Җәмәгать фикер алышуларының башлануы турында белдерүне Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http://agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының мәгълүмат стендларына урнаштырырга;

3.3. Проект буенча фикер алышу нәтиҗәләре буенча җәмәгать фикер алышулары беркетмәсен һәм җәмәгать фикер алышуларының нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.

3.4. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районы сайтында http://agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре турында бәяләмәне бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А. С. Авдеевка йөкләргә.

**В.В. МАКАРОВ**

Башкаручы:
Л.Р. Хазиева